РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

15 ноябрь, 2024 ел Кукмара ш. № 274

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 23 октябрендәге 10-53/13044 номерлы бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы **карар кабул итте:**

1. Кукмара муниципаль районы Советының 2012 елның 19 декабрендәге 171 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Территориаль планлаштыру схемасына аларга карата генераль планны әзерләү зарурлыгы булмау турында карар кабул ителгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан торак пунктлар чикләре турындагы белешмәләр белән тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертергә.

2. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм расланган документны Россия Федерациясенең территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кукмара муниципаль районы Советының Шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы С.Д. Димитриев